**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ БИТАМАН**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2

**СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
село.Большой Битаман, ул. Московская, 2

тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**26 март 2021ел.** **№ 22**

## Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән ачыклау Тәртибен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Олы Битаман авыл җирлеге Уставы нигезендә, Олы Битаман авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРДЕ:

1. Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән ачыклау Тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы А.Ә.Әминов

Расланган
Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 март № 17 Карары белән

**Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән ачыклау Тәртибе**

**1.** Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау гражданнарны сораштыру яисә аларның имзаларын җыю юлы белән башкарылырга мөмкин.

2. Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау, гражданнарны сораштыру юлы белән, Олы Битаман авыл җирлеге Советы карары белән расланган Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның имзаларын җыю имза кәгазе формасында проект инициаторлары тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә гамәлгә ашырыла. Имза кәгазенә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә имза кәгазенә кул куйган гражданнарның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык кушып бирелә.

4. Имзалар кәгазендә граждан турындагы күрсәткечләр үз кулы белән бары тик кулдан гына язылa, шул ук вакытта карандашлар куллану рөхсәт ителми.

5. Гражданнар имзалары куелган имза кәгазенең һәркайсы проект инициаторлары тарафыннан таныкланырга тиеш. Проектның инициаторы инициатив төркем булса, имза кәгазе инициатив төркем әгъзаларының теләсә кайсысы белән таныклана.

6. Имзалар кәгазьләренә Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы карары белән билгеләнгән инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган Олы Битаман авыл җирлеге территориясендә, территориясе өлешендә яшәүче гражданнарның кимендә 50 %ының имзасы кертелә.

7. Имзалар җыюны төгәлләгәннән соң проект инициаторы тарафыннан имзалар саны санала һәм инициатив проектны яклап гражданнар имзаларын җыю йомгаклары турында беркетмә әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә төзелә (алга таба - беркетмә). Беркетмәгә проект инициаторы имза сала. Проектның инициаторы гражданнарның инициатив төркеме булган очракта, беркетмәгә гражданнарның инициатив төркеменең барлык әгъзалары имза сала.

8. Беркетмә һәм имзалар кәгазьләре инициативалы проект белән бергә Олы Битаман авыл җирлегендә инициативалы проектларны карау эшен оештыруга җаваплы Олы Битаман авыл җирлеге Башкарма комитеты белгеченә Олы Битаман авыл җирлеге Советы карары белән расланган Олы Битаман авыл җирлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, карау, шулай ук конкурс нигезендә сайлап алу Тәртибенә ярашлы рәвештә юллана.

Тәртипкә 1 нче кушымта

Имзалау кәгазе

Без, түбәндә имза куйган Олы Битаман авыл җирлегендә яшәүчеләр, инициатив проектны яклыйбыз

______________________________________________

*(инициатив проектның исеме)*

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспорт белешмәләре (яки аны алыштырчы документ) | Имза һәм кәгазьне имзалау датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Имзаларны таныклыйм:

______________________________________________

*(Ф.И.О., туу датасы, паспорт белешмәләре (яки аны алыштыручы документ),*

______________________________________________

*имзалар җыюны гамәлгә ашыручы затның яшәү урыны адресы)*

«___» __________ 20___ ел

_______________

*(имза)*

Тәртипкә 2 нче кушымта

# Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,_______________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________,

(фамилия, исем, атасының исеме, адресы, аның шәхесен раслаучы төп документның номеры, күрсәтелгән документны тапшыру датасы һәм аны биргән орган турында белешмәләр )

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Олы Битаман авыл җирлеге Башкарма комитетына минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

1. Олы Битаман авыл җирлегенең Башкарма комитеты минем шәхси мәгълүматларны (җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, таратуны (шул исәптән тапшыруны), блоклауны, минем шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруны) документар һәм электрон формада эшкәртергә хокуклы.

2. Эшкәртелүенә әлеге ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар исемлеге: фамилия, исем, атасының исеме, туу датасы, паспортның яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, яшәү урыны адресы.

3. Әлеге ризалыкның гамәлдә булуы сроксыз. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктату шарты булып минем әлеге ризалыгымнан язмача кире алу тора. Олы Битаман авыл җирлегенең Башкарма комитеты шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктата һәм, әгәр шәхси мәгълүматны саклап калу таләп ителмәсә, аларны күрсәтелгән чакыртып алу датасыннан 30 көннән дә артык булмаган вакытта юк итә. Олы Битаман авыл җирлегенең Башкарма комитеты, әлеге ризалык кире алынганнан соң, минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыру өчен гамәлдәге законнар нигезендә ризалык таләп ителмәгән яисә таләп ителмәячәк өлештә дәвам итәргә хокуклы.

Әлеге пункт, әлеге ризалык кире алынганнан соң, минем шәхси белешмәләрне эшкәртүне туктату срогын үзгәртү турында Олы Битаман авыл җирлегенең Башкарма комитеты һәм минем белән килешү булып тора.

4. Олы Битаман авыл җирлегенең Башкарма комитеты инициатив проектны карау максатларында, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләрне үтәү максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртергә хокуклы.

5. Мин шәхси мәгълүматларны өченче затларга аларны эшкәртү өчен әлеге ризалыкның 1 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән әлеге ризалыкның 4 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен тапшыруга ризалык бирәм.

«___» __________ 20___ ел _______________

*(имза)*

Тәртипкә 3 нче кушымта

Беркетмә
инициатив проектны яклауга гражданнарның имзаларын җыю нәтиҗәләре турында
______________________________________________________________________.
*(инициатив проектның исеме)*

Олы Битаман авыл җирлеге башлыгының инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган җирлек территориясенең бер өлешен билгеләү турындагы карары нигезендә имзалар җыю гамәлгә ашырылган территория ___________________________________________________________________.

Күрсәтелгән территориядә яшәүче халыкның гомуми саны – ______________________________________________________________________.

Инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча фикерне исәпкә алу өчен кирәкле имзалар саны – ____________________________________.

Имза кәгазьләре саны– ____________________________________.

Инициатив проектны яклап имзалар кәгазьләрендәге имзалар саны ____________________________________________________________.

Проект инициаторы ____________________ ________________________
*(имза*